ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның тармактан тыш бурычларын исәпкә алып, яшьләр белән эшләүне оештырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара (тармакара) хезмәттәшлеге системасын камилләштерү чараларын күрергә.

2.2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә тиешле эшне камилләштерү максатларында, муниципаль мәдәният, спорт һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре инфраструктурасы куәтеннән файдаланып, яшьләр белән эшләүнең якынча модельләрен, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә яшьләр сәясәте субъектлары тарафыннан яшьләр белән эшләүнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын эшләү мәсьәләсен карарга.

2.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 декабрендәге 3581-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2030 елга кадәр яшьләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәмнең озак сроклы программасын гамәлгә ашыру чараларын күрергә.

2.4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен яшь белгечләрне, авыл яшьләрен беркетү максатларында аларга ярдәм итүнең яңа механизмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү мөмкинлеген карарга.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынган органнары белән берлектә халыкны яшьләр белән эшләү буенча дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр белән тәэмин итү нормативларын эшләргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына яшьләрнең эш белән тәэмин ителүенә җәлеп итүчәнлекне арттыру, яшьләр арасында эшсезлек дәрәҗәсен киметү, мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны эшкә урнаштыру дәрәҗәсен арттыру, шулай ук халыкның социаль киеренке төркемнәрендәге яшьләрнең эш белән тәэмин ителмәве куркынычын киметү максатларында Татарстан Республикасында яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итү механизмнарын камилләштерү чараларын эшләүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары вәкиллекле органнарына, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары тармак органнарының яшьләр белән эшләүдә хезмәттәшлеген оештыруга аерым игътибар итеп, үзләренең утырышларында тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карауны тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

6.1. Яшьләр сәясәте, мәдәният, спорт һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә яшьләр белән системалы эшләүне оештыру һәм камилләштерү максатларында җирле үзидарә органнарының тармакара хезмәттәшлеге механизмнарын эшләргә.

6.2. Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Татарстан Республикасында гамәлдә булган яшьләр торак программаларын һәм проектларын тормышка ашыруны тәэмин итү эшен көчәйтергә.

6.3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә муниципаль дәрәҗәдә яшьләр белән эшләүне гамәлгә ашыручы органнарны кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсен эшләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 10 феврале
№ 1323-VI ДС